**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕРӘШ- ШУРАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**
**IV ЧАКЫРЫЛЫШ LI УТЫРЫШЫ**

**КАРАР**

13 февраль 2025 ел — № 80

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмә хакында «2020елның «16» декабрь 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль законына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы прокурорының 2025 елның 22 гыйнварындагы 02-08-01-2025 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш-Шуран авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмә хакында «2020 елның «16» декабрь 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 13 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль контрактлар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, сатып-алуларның план-графигы нигезендә төзелә (Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый план-графикка кертелергә тиешле сатып алу очракларыннан тыш), һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Керәш-Шуран авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Керәш-Шуран авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Сафиуллин